Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXI-3**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 22 августы

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 23 апрелендәге “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматларын тапшыру хакында” Х-4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

“Коррупциягә каршы тору өлкәсендә дәүләт сәясәтен камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2017 елның 3 апрелендәге 64-ФЗ номерлы Федераль закон, “Муниципаль вазыйфа яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, муниципаль вазыйфаларны яки контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар тапшыру тәртибе турында” 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителүгә бәйле рәвештә, “Коррупциягә каршы тору турында” 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 маендагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсендәге 8 өлеше, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2016 елның 23 апрелендәге “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы

гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматларын тапшыру хакында” X-4 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 16.11.2016 ел XIII-6, 24.07.2017 ел XX-6 номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт сыйфатындагы йөкләмәләре турында мәгълүматларын тапшыру хакында Нигезләмәдә:

1 пунктта түбәндәге эчтәлектәге дүртенче абзацны өстәргә:

“Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан бирелүгә бәйле мөнәсәбәтләргә кагылмый һәм күрсәтелгән вазыйфаны биләүче зат тарафыннан үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар.”;

8 пунктта икенче җөмләне төшереп калдырырга;

1.2) “Балык Бистәсе муниципаль районы” муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәрләр үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүматлар бирергә тиешле вазыйфалар исемлегендә:

2 бүлекнең 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Муниципаль хезмәтнең югары вазыйфасы

Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары.”.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе И.Г. Вәлиев